**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Шомырбаш авыл җирлеге составына керүче Алан-Полян авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

29 ноябрь, 2021 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге Башлыгының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлегенең Алан-Полян авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2021 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы карары нигезендә, 2021 елның 29 нояберендә узган гражданнар җыенының 1 нче номерлы йомгаклау беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлегенең Алан-Полян авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлегенең Алан-Полян авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан һәм тумыштан инвалид, беренче группа инвалид гайре, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә. Тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
   - Алан-Полян авылындагы Я.Емельянова, Центр, Нагорный, Ленин урамнарында юлларны төзекләндерү эшлере өчен.
   - Алан-Полян авылында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру
   - Алан-Полян авылында тирән насос сатып алу һәм урнаштыру
   - Алан-Полян авылында су белән тәэмин итү системасын рәсмиләштерү.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шомарбаш авылы, Совет урамы, 47 йорт; Таулар авылы, Ленин урамы, 50А йорт; Алан-Полян авылы, Я.Емельянов урамы, 6 йорт; Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы авылы, Парк урамы, 10 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче –
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомырбаш авыл җирлеге Башлыгы И.Н.Сафин